**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге составына керүче Татар Буасы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

21 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; Татар Буасы авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү (инвентарь сатып алу) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2024 елның 21 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә, халык җыенында катнашучылар исемлегенә 660 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны-448 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 234 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 36 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Татар Буасы авыл җирлеге составына керүче Татар Буасы авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Татар Буасы авыл җирлегенең Татар Буасы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту; Татар Буасы авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); традицион җирләү урыннарын ремонтлау, киртәләр кору, төзекләндерү (инвентарь сатып алу) өчен тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татар Буасы авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халык җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: ___________ Р.Ф.Йосыпов

Татар Буасы авыл җирлеге

башлыгы ___________________ Р.Ф.Йосыпов